**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«26» 12 2022 ел №4215

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Генераль планы проекты белән килешү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23-25 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Тукай муниципаль районы уставына, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2022 елның 14 декабрендәге халык тыңлаулар беркетмәләренә, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча 2022 елның 14 декабрендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләргә таянып

## КАРАР БИРӘ

1. «ГК-Групп» ҖЧҖ тарафыннан эшләнгән һәм 2022 елның 14 декабрендә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Иске Дөреш, Таулы Дөреш, Октябрь Бүләге авылларында халык тыңлауларында каралган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Генераль планы проекты белән килешергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Генераль планы проектын халык тыңлаулар беркетмәләре һәм халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр белән Тукай муниципаль районы Советына раслауга җибәрергә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин